**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**ГЛАВА МАСАДИНСКОГО**
**СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**
**АКТАНЫШСКОГО**
**МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**
423753, деревня Масады,
ул. Нефтяников ,дом 18 ,
Тел. 3-44-49

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ**
**РАЙОНЫ МЭСЭДЕ АВЫЛ**
**ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ**
423753, Мэсэде авылы,
Нефтяниклар ур.,18 нче йорт.
Тел. 3-44-49

01.11.2019

№2

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

**Актаныш муниципаль районы Мәсәде авыл җирлегенең Мәсәде,Бурсык торак пунктларында гражданнарның үзара салым акчасын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча халык җыенын билгеләү турында**.

“Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ санлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ санлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, “Мәсәде авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставының 25.1 статьясы нигезендә Актаныш муниципаль районы, Мәсәде авыл җирлеге Башлыгы:

**Карар бирә:**

1. 2019 елның 20 ноябрендә 10 сәгать 00 минутка Актаныш муниципаль районының Мәсәде авыл җирлеге Бурсык авылы торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыены билгеләргә.
2. 2019 елның 21 ноябрендә 13 сәгать 00 минутка 1 этапны Актаныш муниципаль районының Мәсәде авыл җирлеге Мәсәде авылы торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыены билгеләргә.(Нефтяников, Речная урамында яшәүче сайлаучылар)
3. 2019 елның 21 ноябрендә 15 сәгать 00 минутта Актаныш муниципаль районының Мәсәде авыл җирлеге Мәсәде авылы торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының 2 нче этабын билгеләргә.(Агыйдел,Новая урамында яшәүче сайлаучылар)

2. . Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга.

-юлларны ремонтлау һәм карап тоту (ком-чуерташ Бистәсе, грейдлау, кардан чистарту)
- янгын краннарын урнаштыру;
- янгын җиңнәрен сатып алу;
- торак пунктларда урам исемнәре һәм йорт номерлары булган күрсәткечләр урнаштыру;
- җирлек торак пунктында Игъланнар тактасы язу һәм эле

- Күмү урыннарын документаль рәсмиләштерү;
-урамнарны яктырту электр челтәрләрен карап тоту
- су челтәрләрен ремонтлау, су чыганакларын лицензияләү.

3. 2020 елда Актаныш муниципаль районының Мәсәде авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертү,көндезге бүлектә укучы студентлардан, 1 төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышында катнашучылардан тыш, бирелгән акчаларны түбәндәге эшләрне үтәү буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерү белән килешәсезме?

«ӘЙЕ «ЮК»

Җыенны Татарстан Республикасы, Актаныш районы, Бурсык авылы,Куйбышев тыкрыгы,4 нче йорт; адреслары буенча үткәрергә.
Татарстан Республикасы,Актаныш районы, Мәсәде авылы, Нефтяников ур.,18 йорт адреслары буенча үткәрергә.

Әлеге карарны Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Мәсәде авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында түбәндәге адреслар буенча игълан итәргә: Мәсәде авылы.Нефтьчеләр урамы, 18 йорт һәм рәсми теркәлгән сайтта www.aktanysh-rt.ru һәм «Актаныш таңнары " район газетасында бастырырга.

3. Әлеге карар ул халыкка игълан ителгән көннән үз көченә керә.

Мәсәде
авыл җирлеге башлыгы Мингазетдинова Ф. Р